**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

17.11.2025 1388-п

Кама поселогында «Тукай су каналы» ЖЧҖ №1 су алу скважинасының санитар саклык зоналарының гамәлдә булуын туктату турында

«Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 06.07.2005 ел, № 325 карары, Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зоналарын билгеләү, үзгәртү, эшчәнлеген туктату турында карарлар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 17.11.2021 ел, № 1251-п боерыгы нигезендә, 2014 елның 7 ноябрендәге ТАТ 028758 ВР серияле җир астыннан файдалануга лицензияне исәпкә алып, боерык бирәм:

1. «Тукай су каналы» ЖЧҖ су алу корылмасының санитар саклык зоналарының гамәлдә булуын туктатырга.
2. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Кама поселогында «Тукай су каналы» ЖЧҖ су алу корылмасының санитар саклык зоналарын билгеләү турында» 24.05.2023 ел, № 633-п боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Хокукый тәэминат бүлегенә әлеге боерыкны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрүне тәэмин итәргә.

4. Дәүләт теркәвенә алганнан соң, каты файдалы казылмалар геологиясе бүлеге җитәкчесенә әлеге боерык күчермәсен түбәндәгеләргә җибәрергә:

- «Тукай су каналы» ЖЧҖ;
- «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» ФБУ филиалына, – санитар саклык зонасын туктату турындагы белешмәләрне Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертү өчен;
- Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы башкарма комитетына;
- Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгына.

Министр А.В. Шадриков